**Министерство образования и науки РТ**
**Государственное автономное профессиональное образовательное учреждение «Апастовский аграрный колледж»**

Приложение:
к ОПОП по профессии 13.01.10
Электромонтер по ремонту и
обслуживанию электрооборудования
(по отраслям)

Утверждаю:
Директор колледжа
И.А. Нигматзянов И.А.
__________________________
Приказ №72/1 от 31.08 2022г.

# Комплект контрольно-оценочных средств

**ОУД 10 Родной язык**
по профессии 13.01.10 Электромонтер по ремонту и обслуживанию электрооборудования (по отраслям)

квалификация: электромонтер по ремонту и
обслуживанию электрооборудования
форма обучения – 1 год 10 месяцев
на базе основного общего образования

Пгт Апастово, 2024

**Министерство образования и науки РТ**
**Государственное автономное профессиональное образовательное учреждение «Апастовский аграрный колледж»**

Приложение:
к ОПОП по профессии 13.01.10
Электромонтер по ремонту и
обслуживанию электрооборудования
(по отраслям)

Утверждаю:
Директор колледжа
И.А. Нигматзянов И.А.

___________________________

Приказ №__ от _________2022г.

# Комплект контрольно-оценочных средств

**ОУД 10 Родной язык**
по профессии 13.01.10 Электромонтер по ремонту и обслуживанию электрооборудования (по отраслям)

квалификация: электромонтер по ремонту и
обслуживанию электрооборудования
форма обучения – 1 год 10 месяцев
на базе основного общего образования

Пгт Апастово, 2024

**СОДЕРЖАНИЕ**

| | | |
|---|---|---|
| **1.** | Общие положения | **3** |
| **2.** | Показатели оценки результатов освоения дисциплины, формы и методы контроля и оценки | **3** |
| **3.** | Контрольно-оценочные материалы | **5** |
| **3.1.** | Текущий контроль | **5** |

## 1. Общие положения

Контрольно-оценочные материалы учебной дисциплины разработаны на основе:

- Федерального государственного образовательного стандарта среднего профессионального образования по профессии 13.01.10 Электромонтер по ремонту и обслуживанию электрооборудования (по отраслям), утвержденный приказом Минобрнауки России от 28 апреля 2023 года №316, входящей в состав укрупненной группы специальностей 13.00.00 Электро-и теплоэнергетика;

- основной профессиональной образовательной программы по профессии 13.01.10 Электромонтер по ремонту и обслуживанию электрооборудования (по отраслям)

-рабочей программы учебной дисциплины ОУД 14 Родной язык

Контрольно-оценочные средства (КОМ) предназначены для контроля и оценки образовательных достижений студентов, освоивших программу учебной дисциплины ОУД 14 Родной язык

КОМ включают контрольные материалы для проведения текущего контроля.

Рассмотрено на педагогическом совете Протокол № 1 от 28.08.2024 г.

## 2. Показатели оценки результатов освоения дисциплины, формы и методы контроля и оценки

Контроль и оценка результатов освоения дисциплины осуществляется преподавателем в процессе проведения практических занятий, тестирования, а также выполнения обучающимися индивидуальных заданий.

| **Результаты обучения**<br>**(освоенные умения, усвоенные знания)** | **Формы и методы контроля и оценки результатов обучения** |
|---|---|
| ***уметь:*** применять грамматические нормы и лексический минимум в речи, в т. лдзхзч. в профессиональной; практически пользоваться татарским языком как средством общения в пределах установленного программой словарного и грамматического минимумов, а также указанных в ней сфер общения; быть компетентным в профессиональном общении с носителями татарского языка. | Практические занятия, прослушивание аудио-диалогов, ситуативная беседа, просмотр видеофильмов;<br>работа с книгой, просмотровое и поисковое чтение газетных журнальных статей (со словарем, без словаря) |
| ***знать:*** элементарные грамматические нормы татарского языка и необходимые выражения и речевые конструкции из повседневной речевой практики для рабочих и служащих; | Практические занятия, ведение беседы, составление монологов и диалогов, дискуссия;<br>работа с книгой, просмотровое и поисковое чтение газетных журнальных статей (со словарем, без словаря) |
| ОК 1. Понимать сущность и социальную значимость своей будущей профессии, проявлять к ней устойчивый интерес. | Практические занятия,<br>диалог, монолог, письмо, работа с<br>книгой, просмотровое и поисковое<br>чтение газетных журнальных статей<br>(со словарем, без словаря).<br>Тестирования и контрольные |
| ОК 2. Организовывать собственную деятельность, выбирать типовые методы и способы выполнения профессиональных задач, оценивать их эффективность и качество. | |
| ОК 4. Осуществлять поиск и использование информации, необходимой для эффективного выполнения профессиональных задач, профессионального и личностного развития. | |
| ОК 5. Использовать информационно-коммуникационные технологии в профессиональной деятельности. | |
| ОК 6. Работать в команде, эффективно | |

| | |
|---|---|
| общаться с коллегами, руководством, клиентами. | работы. |
| ОК 7. Брать на себя ответственность за работу членов команды (подчиненных), результат выполнения заданий.<br><br>ОК 8. Самостоятельно определять задачи профессионального и личностного развития, заниматься самообразованием, осознанно планировать повышение квалификации. | |
| | |
| Форма аттестации | **Итоговая контрольная работа** |

**3. Контрольно-оценочные материалы**
**3.1 Текущий контроль**

**1 вариант**

**1.**Наил: Хәерле көн, Азалия! Без сине бик көттек.
Азалия: Исәнме, Наил! Сине күрүемә шатмын! Сезнең гаиләгездә ничә кеше бар?
Наил: Гаиләдә без өчәү: әти, әни һәм мин. Әтиемнең исеме - Ренат, аңа 35 яшь. Әниемнең исеме - Римма, аңа 33 яшь. Ә сезнең гаиләдә ничә кеше?
Азалия: Ә без бишәү: әти, әни, абый, мин һәм энем.
Наил: Әниең кем булып эшли?
Азалия: Әнием - укытучы. Ул балаларны бик ярата, шуңа күрә тырышып эшли. Ял көннәрендә безне итле бәлеш пешереп сыйлый.
Наил: Әтиең кем булып эшли?
Азалия: Әтием заводта 10 ел эшли. Аны эшендә хөрмәт итәләр. Ул эштән соң кайта. Өйгә кайткач, әтием кичке аш ашый.
Наил: Син абыең һәм энең белән дусмы?
Азалия: Мин аларны яратам. Без дус яшибез. Беләсеңме, күптән түгел анын белән “Әкият” татар дәүләт курчак театрына бардык. Анда Кар кызы турында тамаша карадык. Антрактта балалар Кыш бабайга шигырьләр сөйләделәр. Шундый күңелле булды! Абыем унберенче сыйныфта укый. Ул теш табибы

булырга тели. Без бергә әти-әнигә булышабыз. Ә син әти-әниеңә ярдәм итәсеңме?
Наил: Мәктәптән кайткач, урын җыям, савыт-саба юам, тузан суыртам, кибеткә йөрим. Ә син өйдә нәрсә эшләргә яратасың?
Азалия: Мин тәмле ашарга яратам, шуңа күрә пешерергә дә яратам. Көн саен әни эштән кайтканчы, кичке аш әзерлим. Помидор, кыяр, суганнан яшелчә салаты ясыйм. Кызганыч, әниемә өйне җыештырырга күп вакыт кирәк. Мин дә идән юарга яратмыйм, шуңа күрә без ярдәмче сатып алдык. Тузансуырткыч робот – гаиләбезнең яңа дусты.

**1. Дөрес җавапны табыгыз.**

Наил нишли?
А) шигырь сөйли
Ә) кибеткә йөри
Б) ашарга пешерә

**2. Текстка туры килгән җавапларны табыгыз.**

А) Наилнең әтисенә 35 яшь.
Ә) Азалиянең абыйсы табиб булырга хыяллана.
Б) Наил – гаиләбезнең яңа дусты.
В) Азалия әнисе белән кичке аш әзерли.
Г) Наил әти-әнисенә булыша.

**3.Тәңгәллекләр урнаштырыгыз.**

| | |
|---|---|
| 1) Наилнең әнисенә | А) хөрмәт итәләр. |
| 2)Азалиянең әтисен | Ә) театрга барган |
| 3) Азалия энесе белән | Б) 33 яшь |
| 4) Азалиянең әтисе | В) соң кайта |

**Җавап: 1) _____2)___3) __4) _**

**4. Дөрес җавапны табыгыз.**

Азалия нигә пешерергә ярата?

А) сыйларга ярата

Ә) ашарга ярата
Б) савыт-саба юарга ярата

**5. Дөрес җавапны табыгыз.**
Балалар кемгә шигырьләр сөйләгәннәр?
А) Азалиягә
Ә) Кар кызына
Б) Кыш бабайга

**6. Дөрес җавапны языгыз. Җавапны бер сүз елән языгыз.**
**Азалиянең әнисе кемнәрне бик ярата?**

Ответ/ Җавап: ________________________________.

**7. Дөрес җавапны табыгыз.**
Азалия энесе белән кайчан театрга барган?
А) әнисе эштән кайтканчы
Ә) мәктәптән кайткач
Б) күптән түгел

**8. Текстка туры килгән җавапларны табыгыз.**
А) Наилнең гаиләсендә өч кеше.
Ә) Азалиянең әнисе балалар укыта.
Б) Азалия ярдәмчел түгел.
В) Азалия теш табибына барган.
Г) Наил урын җыярга яратмый.

***Дөрес җаваплар***

| № задания | ответы |
|---|---|
| 1 | Ә |
| 2 | А Ә Г |
| 3 | 1) Б 2) А 3) Ә 4) В |
| 4 | Ә |
| 5 | Б |

| | |
|---|---|
| 6 | БАЛАЛАРНЫ |
| 7 | Б |
| 8 | АӘ |

**2 вариант**

**1.**Алия: Дамир, мин сине туган көнгә чакырырга телим. Иртәгә кичке 6 да безгә кунакка кил.
Дамир: Синең туган көнең 2 айдан гына бит. Кемнең туган көне?
Алия: Әниемнеке. Аңа 34 яшь тула. Без бүген үк бәйрәмгә әзерләнә башладык. Өстәлгә кашыклар һәм чәнечкеләр куйдык. Чынаякларны сөлге белән сөрттек. Яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне юып куйдык. Зур тәлинкәләргә пәрәмәчләр куячакбыз. Гөбәдияне зур табада пешерәчәкбез. Ә син нәрсә ашарга яратасың?
Дамир: Мин туңдырма яратам, кыстыбый да ашыйсы килә. Әниеңә нәрсә бүләк итәсең? Аңа нәрсә ошый, Алия?
Алия: Бүләкне чын күңелдән сайларга кирәк. Ул кирәкле һәм истәлекле булырга тиеш, шуңа күрә мин әниемә китап белән матур чәчәкләр бүләк итәчәкмен. Матур булып истә калсын өчен, китапны кечкенә тартмага салып бирәчәкмен. Туган көн – ул бүләкләр көне. Әнинең бик бәхетле көне булачак.
Дамир: Ә мин нинди бүләк алырга белмим...
Алия: Мин беләм! Узган атнада ул яулык алырга теләгән иде. Ошаган төсе булмады. Яулык – иң яхшы бүләк! Әнием бу бүләк турында күптән хыяллана.
Дамир: Чынлапмы?
Алия: Әлбәттә, мин аны яхшы беләм. Һичшиксез, әнием бүләкне шатланып кабул итәчәк.
Дамир: Ярый, киңәшең өчен рәхмәт.
Алия: Иртәгәгә хәтле! Сау бул!
Дамир: Очрашырбыз!

1. **Дөрес җавапны табыгыз.**

Алия нишли?
А) кунакка бара
Ә) яулык ала
Б) туган көнгә әзерләнә

**2. Текстка туры килгән җавапларны табыгыз.**

А) Алиянең туган көне ике айдан түгел.
Ә) Дамир кыстыбый яратмый.
Б) Алия энисенә тартма бүләк итәчәк.
В) Дамир Алиягә киңәше өчен рәхмәт әйткән.
Г) Дамир иртәгә кунакка киләчәк.

**3.Тәңгәллекләр урнаштырыгыз.**

| | |
|---|---|
| 1) Иртәгә әниемнең | А) төсе ошамаган. |
| 2) Әнигә яулыкның | Ә) киңәш бирә. |
| 3) Алия дустына | Б) туган көне. |
| 4) Алия Дамирны | В) кунакка чакыра |

**Җавап: 1) _____2)___3) __4) _**

4. **Дөрес җавапны табыгыз.**

Иртәгә кемнең бәхетле көне булачак?

А) әнинең
Ә) Алиянең
Б) Дамирның

5. **Дөрес җавапны табыгыз.**

Наил нәрсә ашарга ярата?
А) пәрәмәч
Ә) туңдырма
Б) җиләк-җимеш

6. **Дөрес җавапны языгыз.Җавапны бер сүз белән языгыз.**
   **Алия китапны нәрсәгә салачак?**

Ответ/ Җавап: __________________________________.

7. **Дөрес җавапны табыгыз.**
   Алия әнисе белән бәйрәмгә кайчан әзерләнә башлаган?

А) иртә белән
Ә) кичке 6 да
Б) бүген

8. **Текстка туры килгән җавапларны табыгыз.**
   А) Алиянең әнисенә 34 яшь тулачак.
   Ә) Алар кашык-чәнечкеләрне юганнар.
   Б) Бүләк истәлекле, кирәкле булырга тиеш.
   В) Әнисе яулык турында хыялланган.
   Г) Дамир бүләккә шатланган.

***Дөрес җаваплар***

| № задания | ответы |
|---|---|
| 1 | Б |
| 2 | ВГ |
| 3 | 1) Б 2) А 3) Ә 4) В |
| 4 | А |
| 5 | Ә |
| 6 | ТАРТМАГА |
| 7 | Б |
| 8 | АБВ |

**Вариант №1**

**2 нче бүлек.**

**Укыгыз һәм биремнәрне үтәгез.**

Халык хуҗалыгында урманның әһәмияте бик зур.Ул безгә ягулык та ,төзү материаллары да , кәгазь дә һәм башка кирәк-яраклар бирә. Урманда кошлар,төрле җәнлекләр яши.Без урманнан гөмбә,чикләвек һәм җиләкләр җыябыз.Урман үзенең яшел яфраклары белән һаваны сафландыра,сәламәтлегебезне саклый.

Урман корылыкка каршы көрәшергә,иген уңышын күтәрергә дә ярдәм итә.Шуңа күрә дә урманны саклауга бик нык игътибар итәргә кирәк.

1. **Текст нәрсә турында?**
   А) урман
   Ә)кошлар
   Б) халык хуҗалыгы

2. **Урманда үз-үзенне ничек тотарга кирәк ?**

   А) агачларны сындырырга
   Ә)урманны сакларга
   Б) учак ягарга

3. **Урман безнең сәламәтлеккә файда китерәме? Җавапны бер сүз белән языгыз.**

   Ответ/Җавап:_______________________________

4. **Авторның фикерен дәвам итегез.**

   Урман ..........................................................................................ярдәм итә.

5. **Бу фикер текстка туры киләме?**

Урман безгә кирәкле материаллар бирми. **Әйе/Юк**

6. **Урманда нәрсәләр үсә?**

А) бәрәңге,кишер,суган

Ә)җиләк,чәчәк,чүгендер

Б) гөмбә,чикләвек.җиләк

7. **Кайсы фикер дөрес түгел.?**

   1. Кешелек өчен урманның әһәмияте бик зур.
   2. Кешелек өчен урманның әһәмияте зур түгел.

8. **Кайсы сүзтезмәдә хата бар ?**
   А) агач яфраклары
   Ә) агачның яфраклары
   Б) агачы яфраклар

9. **Урман безгә ягулык материаллары бирә.**
   А) Текстка туры килә.
   Ә) Текстка туры килми

**10. Дөрес сүзтезмәне курсәтегез.**
А) яшел яфраклы агачлар
Ә) яшел яфрак агачлары

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | А | 6 | Б |
| 2 | Ә | 7 | 2 |
| 3 | КИТЕРӘ | 8 | Б |
| 4 | СӘЛАМӘТЛЕККӘ | 9 | А |
| 5 | ӘЙЕ | 10 | А |

**Вариант № 2**

**2 нче бүлек.**

**Укыгыз һәм биремнәрне үтәгез.**

Кояш чыкты,җир йөзен җылытты.Урманнарда, яшел аланнарда чәчәкләр ал,кызыл,сары,зәңгәр керфекләрен ачып кояшка карадылар.Әнә инде эшчән бал корты да,чәчәктән-чәчәккә кунып,татлы ширбәт җыя.Төрле бизәкле күбәләкләр саф һавада уйныйлар.Җитез тиен ботактан-ботакка сикерә,чикләвек эзли. Куе булып кура җиләге үскән чытырманлыкта йөнтәс аю җиләк ашап йөри.

1. **Текст нәрсә турында?**
   А) урман
   Ә) җәй
   Б) чәчәкләр

2. **Җәй җиткәч табигать ничек үзгәрә ?**

   А) салкынайта
   Ә) җылыта
   Б) агачлар яфракларын коя

3. **Бал кортлары җәй җиткәч нишли? Җавапны бер сүз белән языгыз.**

   Ответ/Җавап:________________________________

4. **Авторның фикерен дәвам итегез.**

Җәй көне ............................................................................

5. **Бу фикер текстка туры киләме?**
Хайваннар йокыга тала. **Әйе/Юк**

**6. Аю нәрсә ашап йөри?**
А) чикләвек

Ә)чәчәк

Б)җиләк

**7. Кайсы фикер дөрес түгел.?**

1.Кояш чыккач, табигать уяна
2. Кояш чыккач, урамда салкынайтты.

**8. Кайсы сүзтезмәдә хата бар ?**
А) яшел алан
Ә) яшелле аланы
Б) яшь алан

**9. Бал кортлары чәчәкләрдән бал җыя.**
А) Текстка туры килә.
Ә) Текстка туры килми

**10. Дөрес сүзтезмәне курсәтегез.**
А) урман чәчәкләре
Ә) урман чәчәке

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Ә | 6 | Б |
| 2 | Ә | 7 | 1 |
| 3 | БАЛ ҖЫЯ | 8 | Ә |
| 4 | ҖЫЛЫ | 9 | А |
| 5 | ЮК | 10 | А |